| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ЧУТЕЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЧҮТИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 ноябрь 2021 ел Чүти ав. № 18

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Чүти авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2021 елның 21 нояберенэ 11 сәг 00 минутка Чүти авылы Кооперативная, 37 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлегенең үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***беренче этабын*** билгеләргә.

2. 2021 елның 22 нояберенэ 11 сәг 00 минутка Чүти авылы Үзәк урамы , адресы буенча урнашкан ООО " Август-Азнакаево " терлекчелэр йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлегенең үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***икенче этабын*** билгеләргә.

3. 2021 елның 23 нояберенә 11 сәг 00 минутка Чүти авылы Куйбышева, 7 йорт адресы буенча урнашкан Мәчет бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлегең үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***өченче этабын*** билгеләргә.

4. 2021 елның 24 нояберенэ 11 сәг 00 минутка Чүти авылы, Кооперативная урамында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл жирлегең үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

5. 2021 елның 25 нояберенэ 11 сәг 00 минутка Чүти авылы Кооперативная , 37 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль

районының Чүти авыл җирлегенең үзара салым алып бару мәсьәләре буенча гражданнар җыенының ***бишенче этабын*** билгеләргә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны урыны буенча Чүти авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, урамнарны яктыртуны ремонтлау;
- материаллар сатып алып, паркны төзекләндерү;
- жирлекнең торак пунктлары чүплекләре территорияләрен чистарту;
- материаллар сатып алып җәяүлеләр өчен күперләрне ремонтлау;

*б) янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүне оештыру::*

- Чүти авылында янгын сүндерү машинасын,җиһазларын,бүлмәләрен һәм ДПО хезмәткәрен тоту;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

*г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:*

- материаллар сатып алып, зиратларны чистарту һәм ремонтлау.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

7.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Чүти авыл җирлеге Башлыгы П.П.Тараканов